**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘЙРӘКӘТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**№25 КАРАР 2019 ел 26 ноябрь**
**Бәйрәкәтамак ав.**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге “Җир салымы турында” №22 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы һәм 2019 елның 29 сентябрендәге «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 22 номерлы «Җир салымы турында» карарына (2015 елның 23 маендагы №10, 2015 елның 15 октябрендәге № 9 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. "Салым ставкалары" дип аталган 2 маддәнең 1 пунктында:

2 маддәне төшереп калдырырга;

3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен булдырылган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җирләр, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге " Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында " 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә - 0,15%.";

5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Торак фонды биләгән җирләргә карата (торак фондына кагылмаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктан тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләре мөнәсәбәтендә (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) – 0,25 %;

6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җирләр мөнәсәбәтендә - 0,25%”.

1.2. «Салым түләү тәртибе һәм сроклары» дигән 5 маддәне төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 октябрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге

Советының "Җир салымы турында" № 222 карарына үзгәрешләр кертү турында " карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, муниципаль районның рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарылыррга һәм ул Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырылырга тиеш.

Әлеге Карарның 1 пункты - 2020 елның 1 гыйнварыннан , 1.2 пункты - 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, әмма рәсми басылып чыккан көненнән соң, бер ай вакыт узарга тиеш.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р.Фәйзрәхманов.